**СОВЕТ ПЕСЧАНО-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422625 с. Песчаные Ковали,
ул. Октябрьская, д.9 а
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс ) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОМЛЫ КАВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

422625 Комлы Ковал авылы,
Октябрьск урамы, 9 а нчы йорт,
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс ) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**№ 135** **2019 елның 7 октябреннән**

# Р Е Ш Е Н И Е

# КАРАР

**"Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр кертү турында" Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлеге Советы карары проекты хакында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы һәм «муниципаль берәмлекләр уставларын дәүләт теркәвенә алу турында» 21.07.2005 елдагы 97-ФЗ номерлы Федераль законнар, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Комлы Ковал авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Кушымта нигезендә Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлеге Уставына үзгәрешләр кертергә.
2. Әлеге карарны «Камская новь» («Кама ягы») район газетасында, махсус мәгълүмат стендларында һәм интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга (игълан итәргә): http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Комлы Ковал авыл җирлеге Советы Рәисе - Башлыгы Н.С.Гыйләҗетдиновка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Комлы Ковал авыл җирлеге**
**Башлыгы, Совет рәисе** **Н.С.Гыйләҗетдинов**

**Татарстан Республикасы**
**Лаеш муниципаль районы**
**Комлы Ковал авыл җирлеге**
**Советының 2019 елның 7 октябрендәге**
**135 номерлы карарына Кушымта**

## “Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы Ковал авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр”

23 статьяның 9 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә: «9. «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясында каралган гражданнар җыены анда әлеге торак пунктта яшәүчеләрнең сайлау хокукына ия булган яртысыннан артыграгы катнашуда вәкаләтле, әлеге Устав нигезендә гражданнар җыены Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Комлы Ковал авылында гражданнар җыенын әзерләү һәм уздыру тәртибе турында Нигезләмә белән расланган тәртиптә гражданнар җыенын үткәрү турында Карар кабул ителгән көннән бер айдан да артмаган вакыт эчендә уздырыла. Шул ук вакытта элек гражданнар җыенында катнашкан затлар тавыш бирүдә киләсе этапларда катнашмый.»